**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2019 Балык Бистәсе штп № 185пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары белән расланган төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә үзидарәлек хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 21 июнендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан үзидарәлек хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында” 96пи номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 гыйнварындагы 33пи номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалануга рөхсәт бирү буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2.5 пунктының 5 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт һәи үзидарәлек хезмәтләре бердәм порталын һәм (яки) дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре төбәк порталын файдаланып язма рәвештә яки электрон документ рәвешендә тиңдәшле күчемсез мөлкәт милекчесенең яки 2006 елның 13 мартындагы “Реклама турында” 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 маддәсе 5,6,7 өлешләрендә күрсәтелгән законлы иясенең, әгәр мөрәҗәгать итүче күчемсез мөлкәтнең милекчесе яки башка бер законлы иясе булып тормаса, әлеге мөлкәткә реклама конструкциясен тоташтыруга ризалыгын раслау. Реклама конструкциясен урнаштыру һәм файдалану өчен күпфатирлы йортта бүлмә милекчеләренең уртак мөлкәтен файдалану кирәк булу очрагында әлеге милекчеләрнең ризалыгын раслаучы документ булып күпфатирлы йорттагы бүлмә милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә торак-коммуналь хуҗалыгы

дәүләт мәгълүмати системасын файдаланып читтән торып тавыш бирү беркетмәсе тора. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча әлеге ризалыкны алуны раслаучы документны тапшырмау очрагында , ә тиндәшле күчемсез мөлкәт дәүләт яки үзидарәлек милкендә булса, муниципаль районның җирле үзидарә органы яки шәһәр округының җирле үзидарә органы мондый ризалыкның булуы турында мәгълүматларны вәкаләтле органнан соратып алдыра”;

1.2) 2.5 пунктының 3 пунктчасын көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 гыйнварындагы 36пи номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1) 1.5 пунктының 5 абзацы 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

“ эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйләнмәгән максатлар өчен физик затка бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзүнең, реконструкцияләүнең яки бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән бакча җир кишәрлегендә торак йорт, бакча йорты, хуҗалык каралтылары төзүнең, реконструкцияләүнең;”;

2.2) 1.5 пунктының 13 абзацын төшереп калдырырга;

2.3) ) 1.5 пунктының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“төзүче – үзенеке булган җир кишәрлегендә яки башка хокукый хуҗаның җир кишәрлегендә төзүне, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауны, капиталь төзелеш объектларын сүтүне, шулай ук инженерлык тикшеренүләре үтәүне, аларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өчен проект документациясен әзерләүне тәэмин итүче физик яки юридик зат (аңа дәүләт (үзидарәлек) милке капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), Атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, Космик эшчәнлек буенча "Роскосмос" дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары яки җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда килешүләр нигезендә үзләренең дәүләт (үзидарәлек) заказ бирүче вәкаләтләрен тапшырган). Төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарда күздә тотылган үз функцияләрен техник заказ бирүчегә тапшырырга хокуклы”.

2.4) 1.5 пунктының 4 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

“техник заказ бирүче – төзүче тарафыннан вәкаләт бирелгән һәм төзүче исеменнән инженерлык эзләнүләрен башкару турында, проект документациясе әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү турында шартнамәләр төзи, күрсәтелгән эш төрләрен үтәүгә заданиеләр әзерли, инженерлык эзләнүләрен башкаручы һәм (яки) проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтүне башкаручы затларга күрсәтелгән эш төрләрен үтәү өчен материаллар һәм документлар бирә, проект документациясен раслый, капиталь төзелеш объектларын

кулланылышка кертүгә рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалый, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда күздә тотылган башка функцияләрне гамәлгә ашыра (алга таба – техник заказ бирүченең функцияләре). Техник заказ бирүченең функцияләре инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш проектлаштыруы, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, сүтү өлкәсендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 47 маддәсенең 2.1 өлешендә, 48 маддәсенең 4.1 өлешендә, 52 маддәсенең 2.1 һәм 2.2 өлешләрендә, 55.31 маддәсенең 5 һәм 6 өлешләрендә күздә тотылган очраклардан гайре, фәкать тиңдәшле үзкөйләнүле оешма әгъзасы тарафыннан гына башкарылырга мөмкин;”

2.5) 2.5 пунктының 20, 21, 22 абзацларын төшереп калдырырга;

2.6) 2.5 пунктының 37 абзацында “һәм дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталы” сүзләреннән соң “һәм Күпфункцияле үзәк аша” сүзләрен өстәргә;

2.7) 2.9 пунктының җиденче, сигезенче абзацларын төшереп калдырырга;

2.8) 2.5 пунктының 4 пунктчасында “яки индивидуаль торак төзелеше объектының тышкы кыяфәтен тасвирлауның” сүзләрен төшереп калдырырга;

2.9)2.6 пунктының “Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

1)җир кишәрлегенә хокук урнаштыручы документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, ачык сервитут билгеләү турында карар;

2) Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән очракларда дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), Атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясе, Космик эшчәнлек буенча "Роскосмос" дәүләт корпорациясе, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары яки җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт (үзидарәлек) заказ бирүчесе вәкаләтләрен тапшыру турында бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән килешү булганда,- күрсәтелгән килешү, аның белән төзелгән бу килешү җир кишәрлегенә хокукый хуҗаның хокукын билгеләүче документлары;

3) төзелешкә рөхсәт алуга гариза тапшырган көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы яки линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелү очрагында территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау (линияле объекты төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документацияләр әзерләү кирәк булмаган очраклардан гайре) проекты реквизитлары, урнаштыру өчен җир кишәрлеге барлыкка китерү кирәк булмаган линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проекты реквизитлары;

4) проект документациясендәге материаллар;

а) аңлатма язуы;

б) җир кишәрлеген планлаштыручы оешманың капиталь төзелеш объектының, аңа керү юллары һәм үтемнәрнең, ачык сервитут чикләренең, археологик мирас объектларының урнашу урынын билгеләп җир кишәрлегенең

шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган схемасы;

в) җир кишәрлеген планлаштыручы оешманың линияле объектларга туры китереп территорияне планлаштыру буенча документация составында расланган кызыл линияләр чикләрендә линияле объектның урнашуын раслаучы схемасы;

г)архитектура чишелешләре;

д) инженерлык җиһазы турында мәгълүматлар, капиталь төзелешнең проектлаштырылучы объектын инженерлык-техник тәэминат челтәрләренә ялгау (технологик тоташтыру) урыннарын билгеләп инженерлык-техник тәэминат челтәрләренең җыелма планы;

е) капиталь төзелеш объектын төзү оешмасы проекты;

ж) капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү (җимерү) буенча эшләрне оештыру проекты;

з) проект документациясенә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенә ярашлы рәвештә экспертиза үткәрелмичә күрсәтелгән объектларның төзелүе, реконструкцияләнүе очрагында инвалидларның сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм башка социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга керү, үтү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар исемлеге;

4) Капиталь төзелеш объектының проект документациясенә экспертизаның уңай бәяләмәсе (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48 маддәсенең 12.1 өлешендә күздә тотылган очрактагы төзелешнең аерым этапларына карата), әгәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенә ярашлы рәвештә андый проект документациясе экспертиза узарга тиеш булса, Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, Шәһәр төзелеше кодексының 49 маддәсенең 6 өлешендә каралган очракларда проект документациясенә дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе;

5) рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылышка рөхсәт (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40 маддәсе нигезендә төзүчегә андый рөхсәт бирелгән очракта);

6) тәңгәллек сертификатлары бердәм реестрыннан мәгълүматлар (проект документациясенә дәүләти булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсе бирелгән очракта проект документациясенә дәүләти булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затның аккредитациясе турында);

7) капиталь төзелеш объекты төзү очрагында Россия Федерациясе законнары нигезендә аның урнашуы белән бәйле рәвештә территорияне файдалануның аерым шартлардагы зонасы билгеләнергә тиеш яки капиталь төзелеш объектын реконструкцияләү очрагында аның нәтиҗәсендә реконструкцияләнгән объектка карата территорияне файдалануның аерым шартлардагы зонасы билгеләнергә тиеш яисә элек билгеләнгән территорияне

файдаланунык аерым шартлардагы зонасы үзгәртелергә тиеш булганлыктан территорияне файдаланунык аерым шартлардагы зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карарнык күчермәсе;

8) РФ Шәһәр төзелеше кодексынык 48 маддәсенең 12 өлеше 3 пунктында күздә тотылган капиталь төзелеш объекты проект документациясенең тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларынык архитектур чишелешләренә карата федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата шәһәр төзелеше регламенты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында Россия Федерациясе субъектынык мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма органы бәяләмәсе (линияле объект булмаган һәм төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта).

Әлеге пунктта күрсәтелгән документлар (аларнык күчермәләре яки алардагы мәгълүматлар) Бүлек тарафыннан күрсәтелгән документлар алар карамагында булган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан, әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә үзе тапшырмаса, төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гариза алынган көннән өч эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алдырыла.

Гариза бирүче тапшырырга хаклы документларнык алыну ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентнык 2.5 пункты белән тәгаенләнгән.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка бүтән оешмалар карамагындагы югарыда санап кителгән документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела.

Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмау гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигез булып тормый.”;

2.10) 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.4.1. Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәгеләрне җибәрү турында электрон рәвештә запрослар юллый:

1) Күчемсез милекнең (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында гомумкерү мөмкин булган мәгълүматларны үз эченә алган) Бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрне;

2) Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын;

3) Рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәтләрне (РФ Шәһәр төзелеше кодексынык 40 маддәсенә ярашлы рәвештә андый рөхсәт төзүчегә бирелгән очракта);

4)Тәңгәллек сертификатлары бердәм реестрыннан мәгълүматларны;

5) Проект документациясенә дәүләт экспертизасынык уңай бәяләмәсен.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар үзидарәлек хезмәте күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырылалар.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына юлланган запрослар.”;

2.11) 1.5 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гариза бирүче – дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органга яки үзидарәлек хезмәтләре күрсәтүче органга яисә 2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ Федераль законның 1 маддәсенең 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларга яки дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтү турында запрос белән, шул исәптән Федераль законның 15.1 маддәсе белән билгеләнгән тәртиптә телдән, язма яки электрон рәвештә чагылдырып Федераль законның 2 маддәсе 5 пунктында күрсәтелгән оешмаларга мөрәҗәгать итүче физик яки юридик зат (дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнарыннан, дәүләти бюджеттан тыш фондлар органнары һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан гайре) яки аларның вәкаләтле вәкилләре;”;

2.12) 1 номерлы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Капиталь төзелеш объектларын
төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт
бирү буенча үзидарәлек хезмәте
күрсәтү Административ
регламентына кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Башкарма
комитет җитәкчесе
______________________________-ка (-га)
(Ф.И.А..и.)
_____________________________-тан (-дан)
____________________________________
____________________________________
(физик зат өчен: фамилия, исем һәм
(булса) атасының исеме, гариза
бирүченең яшәү урыны, гариза бирүченең
шәхесен таныклаучы документның
реквизитлары; юридик зат өчен: гариза
бирүченең исеме (аталышы) һәм урнашу
урыны, юридик затларның бердәм дәүләт
реестрында юридик затның дәүләт теркәлүе
турында язманың дәүләт теркәү номеры,
салым түләүченең таныклау номеры (ИНН),
гариза бирүче булып чит ил юридик заты
торган очраклардан гайре)
_____________________________________
(гариза бирүче белән элемтә өчен почта
адресы һәм (яки) электрон почта адресы)

**Төзү эшләренә рөхсәт бирү турында**
**гариза**

________________________ ай срокка
_______________________________________________адресы буенча җир кишәрлегендә:
_____________________________________________________________________________
(шәһәр, район, урам, участок номеры)
төзелешкә /реконструкцияләүгә рөхсәт бирүегезне үтенәм.
(кирәклесенең астына сызарга)
_____________________________________________________________________________
(объектның исеме)
Төзелеш (реконструкция) ____________________”___”_________ел №_________________

(документның исеме)

нигезендә гамәлгә ашырылачак.

Җирдән файдалану хокукы беркетелгән ______________________________

(документның исеме)

______________________ “____” ________ ел № ________

Объект төзелешенә проект документациясе эшләнгән ______________________________

(проект оешмасының исеме, ИНН, юридик һәм почта адреслары,

______________________________

җитәкченең Ф.И.А.и. , телефон номеры, банк реквизитлары

______________________________

(банкның исеме, р/с, к/с, БИК))

проект эшләрен башкаруга хокукы булган, беркетелгән ______________________________

______________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме)

, һәм билгеләнгән тәртиптә

“____” ______________ ел № ______________ кызыксынучы оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән килештерелгән:

– дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе алынган № ________________

“____” ______________ ел

– җир кишәрлеген планлаштыру оешмасының схемасы килештерелгән ______________

______________________ № __________ “____” ____________ ел

(оешманың исеме)

Проект-смета документациясе расланган ______________________________

______________________ № __________ “____” ____________ ел

Өстәмә мәгълүмат җиткерәбез:

Төзүче тарафыннан төзелешне (реконструкция, капиталь ремонт) финанслау гамәлгә ашырылачак ______________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр подряд (хуҗалык) ысулы белән түбәндәге шартнамә нигезендә алып барылачак “____” ______________ 20____ ел № ______________________________

______________________________

(оешманың исеме, ИНН,

______________________________

юридик һәм почта адреслары, җитәкченең Ф.И.А.и. , телефон номеры,

______________________________

банк реквизитлары ( банк исеме, р/с, к/с, БИК))

Төзү-монтажлау эшләрен башкару хокукы беркетелгән ______________________________

______________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме )

______________________________

“____” ______________ ел № ____________________

Төзелеш эшләре җитәкчесе

итеп __________ “ ____” ____________ ел ______№______

боерык белән билгеләнде ______________________________

(вазыйфа, фамилия, исем, атасының исеме)

______________________ махсус белеме һәм төзелештә _ ел эш стажлы

(югары, урта)

Төзелеш контроле “___” ____________ел № ___

лы шартнамә нигезендә гамәлгә ашырылачак

(оешманың исеме, ИНН, юридик һәм

почта адресы, җитәкченең Ф.И.А.и, телефон номеры, банк

реквизитлары (банкның исеме, р/с, к/с, БИК))

заказ бирүче (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелгән

(документ һәм аны биргән оешманың исеме)

№ ____________ “_____” ______________________ ел

Әлеге гаризада китерелгән мәгълүматлар белән бәйле барлык үзгәрешләр турында __________________________________________________________оешмага хәбәр итүне үз өстемә алам. (вәкаләтле органның исеме)

______________________ ______________ ____________________
(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

“_____” ________________ 20_____ ел

2.13) 2.4 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы төзелешкә рөхсәт бирүгә срокны җиде эш көненнән арттырмауны күздә тота. Бүлек үзидарәлек хезмәтен биш эш көне эчендә күрсәтә”.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 29 гыйнварындагы 22пи номерлы карары белән расланган торак (торак булмаган) урынны торак булмаганга (торакка) күчерү (күчерүне кире кагу) турында хәбәрнамә бирү буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән үзидарәлек хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итүнең зарурлыгын да исәпкә алып, туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта үзидарәлек хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Тору урынын (торакны, бүлмәне) күчерү яки күчерүне кире кагу турындагы карар тору урыннарын күчерүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан тиңдәшле гаризаны һәм 2.5 пунктчасы нигезендә тапшырылган бүтән документларны карау нәтиҗәсендә документларны (аларны тапшыру бурычы гариза бирүчегә йөкләнгән) әлеге органга тапшырган көннән соң кырык биш көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.<br>2.5 пунктчасында күрсәтелгән документларны гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәк | Россия Федерациясе Торак кодексы (23 маддәнең 4 өлеше) |

| | | |
|---|---|---|
| | аша тапшыру очрагында торак урынны күчерү яки күчерүне кире кагу турында карар кабул итү срогы күпфункцияле үзәк тарафыннан андый документларны торак урыннарын күчерүне гамәлгә ашыручы органга тапшырган көннән исәпләнә. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү срогын туктату күздә тотылмаган. | |

3.2) 2.9 пунктының 5 пунктчасында “торак урынның” сүзләрен “күпфатирлы йортлардагы бүлмәләрнең” сүзләренә алмаштырырга;

3.3) 2 номерлы кушымтада “бинаны үзгәртеп кору (үзгәртеп планлаштыру) буенча эшләр исемлеге” сүзләрен “күпфатирлы йортта” сүзләре белән тулыландырырга;

3.4) 2.9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Күрсәтелгән нигез буенча торак бинаны күчерүне кире кагу рөхсәт ителә шул очракта, әгәр торакны күчерүне гамәлгә ашыручы орган күрсәтелгән җавапны алганнан соң андый җавапны алу турында гариза бирүчегә хәбәрнамә җибәрсә, гариза бирүчегә әлеге Кодексның 23 маддәсенең 2 өлеше нигезендә торак бинаны торак булмаганга яки торак булмаганны торакка күчерү өчен кирәкле документны һәм (яки) мәгълүматны тапшырырга тәкъдим итеп гариза бирүчедән хәбәрнамәне җибәргән көннән соң унбиш эш көне эчендә андый документны һәм (яки) мәгълүматны алмаса”.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 10пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1) 2.9 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) Ведомствоара запроска дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы карамагындагы оешманың үзидарәлек хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яки) мәгълүматның булмавын таныклаучы җавабы килеп ирешү, әгәр тиңдәшле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, андый сорала торган документның яки мәгълүматның андый орган яки оешма карамагында булмавы тиңдәшле гражданнарның торакка мохтаҗлар сыйфатында исәптә тору хокукын раслау очракларыннан гайре;”;

4.2) 2.4 пунктында “21 көн [1]” сүзләрен “гариза биргән көннән соң бер ай срокта” сүзләренә алмаштырырга.

4.3) 1-5 кушымталарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Кушымта № 1

Җирле үзидарә органы җитәкчесенә
______________________________
(район, шәһәр исеме)

______________________________________________________________
гр. ____________________________________________ -дан (-тан)
(тулысынча фамилия, исем, атасының исеме)

______________________________________________________________
(адресы буенча шәһәрдә, поселокта, авылда яшәүче,
______________________________________________________________
почта индексы, тулы адрес, контакт телефоны)
______________________________________________________________
(адресы буенча теркәлгән, почта индексы, тулы адрес)
______________________________________________________________
_______________________ бирле
(число, ай, ел)

Гариза.

__________________________________________________________________сәбәпле
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкның сәбәпләрен күрсәтергә)
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(гаиләнең бер кешесенә торак мәйданы белән тәэмин ителеш социаль ипотека
_______________________________________________________________________________
буенча исәпкә кую нормасыннан түбән,
_______________________________________________________________________________
санитар һәм техник таләпләргә җавап бирмәүче торак бинада яшәү)
_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(билгән объектның тибын күрсәтергә: аерып алынган (коммуналь),
_______________________________________________________________________________
бүлмәләр саны)
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Расланган формадагы гаризага социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен гаиләмне исәпкә алу өчен кирәк булган мәгълүматларны эченә алган анкета теркәлә.

Сездән социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен мине составында __ кеше булган гаиләм белән исәпкә алуыгызны үтенәм.

Мин һәм гаиләм әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүгә, алар тарафыннан, шулай ук махсуслашкан оешманың (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының) исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен зарури документларына запроска ризалык бирәбез.

Мин һәм гаиләм әгъзалары безне исәпкә алган очракта гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә алар турында бер ай эчендә язма рәвештә исәп урыны буенча җирле үзидарә органнарына хәбәр тотарга тиеш булуыбыз турында кисәтелдек.

Мин һәм гаиләм әгъзалары гаризада күрсәтелгәннәргә туры килмәүче мәгълүматлар ачыкланган очракта законда билгеләнгән тәртиптә исәптән төшерелүебезгә риза.

Шуның белән тиешле салым органнарында һәм күчемсез мөлкәткә һәм алар белән килешүләргә хокукны дәүләт теркәве буенча органнарда минем керемнәрем һәм милек хокукындагы мөлкәтем турындагы мәгълүматларны тикшерүгә ризалыгымны бирәм.

Гариза бирүче: ______________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме тулысынча, имза)

Гаиләнең хокуктан файдалануга сәләтле әгъзалары:
1.____________________________________________________________
2.____________________________________________________________
3.____________________________________________________________
4.____________________________________________________________
5.____________________________________________________________
6.____________________________________________________________
(Гаиләнең хокуктан файдалануга сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

"___________" ____________ 20__ ел
(Дата сүз белән)

Оешма җитәкчесенә _________________________________
(оешманың исеме)
_______________________________________________________________
(район, шәһәр исеме)
_______________________________________________________________
гр. __________________________________________ -дан (-тан)
(тулысынча фамилия, исем, атасының исеме)
_______________________________________________________________

(адресы буенча шәһәрдә, поселокта, авылда яшәүче,
______________________________________________________________
почта индексы, тулы адрес, контакт телефоны)
______________________________________________________________
(адресы буенча теркәлгән, почта индексы, тулы адрес)
______________________________________________________________
_______________________ бирле
(число, ай, ел)

Гариза.

__________________________________________________________________сәбәпле
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкның сәбәпләрен күрсәтергә)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(гаиләнең бер кешесенә торак мәйданы белән тәэмин ителеш социаль ипотека
______________________________________________________________________________
буенча исәпкә кую нормасыннан түбән,
______________________________________________________________________________
санитар һәм техник таләпләргә җавап бирмәүче торак бинада яшәү)
______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(билгеләнгән объектның тибын күрсәтергә: аерып алынган (коммуналь),
______________________________________________________________________________
бүлмәләр саны)
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Расланган формадагы гаризага социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен гаиләмне исәпкә алу өчен кирәк булган мәгълүматларны эченә алган анкета теркәлә.

Сездән социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен мине составында __ кеше булган гаиләм белән исәпкә алуыгызны үтенәм.

Мин һәм гаиләм әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүгә, алар тарафыннан, шулай ук махсуслашкан оешманың (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының) исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен зарури документларына запроска ризалык бирәбез.

Мин һәм гаиләм әгъзалары безне исәпкә алган очракта гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә алар турында бер ай эчендә язма рәвештә исәп урыны буенча җирле үзидарә органнарына хәбәр тотарга тиеш булуыбыз турында кисәтелдек.

Мин һәм гаиләм әгъзалары гаризада күрсәтелгәннәргә туры килмәүче мәгълүматлар ачыкланган очракта законда билгеләнгән тәртиптә исәптән төшерелүебезгә риза.

Шуның белән тиешле салым органнарында һәм күчемсез мөлкәткә һәм алар белән килешүләргә хокукны дәүләт теркәве буенча органнарда минем керемнәрем һәм милек хокукындагы мөлкәтем турындагы мәгълүматларны тикшерүгә ризалыгымны бирәм.

Гариза бирүче: ____________________________________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме тулысынча, имза)

Гаиләнең хокуктан файдалануга сәләтле әгъзалары:

1.____________________________________________________________
2.____________________________________________________________
3.____________________________________________________________
4.____________________________________________________________
5.____________________________________________________________
6.____________________________________________________________

(Гаиләнең хокуктан файдалануга сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

"___________" ____________ 20__ ел
(Дата сүз белән)

Кушымта № 2

ГАРИЗА БИРҮЧЕНЕҢ АНКЕТАСЫ

1.Гариза бирүченең Фамилиясе,исеме,атасының исеме ______________________________________
(тулысынча)

2.Түбәндәге адрес буенча яшим ________________________________________ ☐☐☐☐
(район, урам, йорт,фатир,бүлмә) (24 бүлек коды)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________
(контакт телефонын күрсәтергә:өй,хезмәт урынындагы)

3. Шәхесне таныклаучы документ ______________________________________
(документ төре)

серия _______ номер ___________кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән _________________

___________________________________________________________________________

4. Туу датасы ______________________________________________ ☐☐☐☐
(число,ай, ел) (7бүлек коды)

5. Туу урыны ______________________________________________ ☐☐☐☐

(шәһәр, район коды)

6. Салым түләученең таныклау номеры ☐☐☐☐☐☐☐☐☐☐☐☐☐
(ИНН) (9 бүлекнең коды – унике тамганың барысын да күрсәтергә)

7. Мәшгульлек: ________________________________________________________ ☐
(гариза бирүче эшләмәсә, мәшгуль булмауның сәбәбен күрсәтергә) (10 бүлек коды)

___________________________________________________________________________
(оешман,предприятие,бүлек,уку урынының тулы исемен күрсәтергә)

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

9. Предприятиенең ИНН——-______________________ ☐☐☐☐☐☐☐☐☐☐
(9 бүлек коды)

___________________________________________________________________________
(гариза бирүче эшләмәү очрагында ИНН га нульләр куела,ягъни
эшләмәүче өчен ННН - 0 000 000 000)

10. Соңгы эш урынында стаж ☐☐ел тәшкил итә
(еллар санын күрсәтергә)

11. Гомуми эш стажы ☐☐ел тәшкил итә
(еллар санын күрсәтергә)

12. Мин һәм минем белән яшәүче гаиләм әгъзалары милек хокукында түбәндәге
торак мәйданын (өлешен) билибез:

_______________________________________
(күпме, кем,кайда, нигезен күрсәтергә)

___________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________ ☐
(20 бүлек коды)

13. Наем шартнамәсе буенча _____________________________________________________

___________________________________________________________________________
(күрсәтергә, кем конкретно)

| №№ п/п | Гариза бирүченең һәм гаилә әгъзаларының Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туганлык мөнәсәбәтләре | Прописка датасы | Аерым финанс-лицевой счетның булуы | Мәйдан (гомуми/ тора торган) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |

14. Милек хокукында ________________________________________________
(күрсәтергә, кем конкретно)

| № п/п | Ф.И.А.и. (тулысысынча) | Туганлык мөнәсәбәтлә-ре | Адрес | Торак хокуклары объекты (код) | Мәйдан (гомуми/ тора торган) | Теркәү датасы милек турындагы таныклык буенча |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | | | | | | |
| 3 | | | | | | |
| 4 | | | | | | |
| 5 | | | | | | |

15. Гариза бирүче һәм аның гаиләсе әгъзалары тарафыннан торак белән соңгы 5 елда торак шартларының начараюына китергән гражданлык-хокукый килешүләр түбәндәге сәбәп буенча эшләнде:

______________________________________________________________________

(ниндиләр икәнен күрсәтергә)

16. Гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең җыелма дәрәҗәсе:

______________________________________________________ ☐

(күрсәтергә:гаиләнең бер әгзасына ничә кв.м туры килә) (15 бүлек коды)

17. Биләгән фатирның төре: ________________________________________

(фатирның төрен күрсәтергә:бүлмәләр саны)

______________________________________________________________ ☐

(төзекләндерү (уңайлы итү)стандартын күрсәтергә) (23 бүлек коды)

______________________________________________________________________

18. Теләсә нинди взносларга (фатир, техника сатып алу, укуга түләү h.б.) банкларның һәм башка бүтән оешмаларның кредит средстволарын файдалану (әйе 1, юк 2) ☐

19. Айлык түләүләр җыенысы ________________________________________

(түләүләрнең конкрет суммасын күрсәтергә)

______________________________________________________________________

20. Түләүләрнең бетү срогы ________________________________________

21. Тутырылган декларация нигезендә айлык җыелма керем гаиләдә

1 кешегә тәшкил итә: __________________________________ ☐

(22 бүлек коды)

(Салым инспекциясе тарафыннан расланган декларация формасы гражданнарны исәпкә алу турында мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлегенә теркәлә)

22. Тәүге взносны кертү мөмкинлеге (пайтупланыш) __________ ☐

(33 бүлек коды)

______________________________________________________________________

(мөмкинлек булса, күрсәтергә, ничә %: 10%, 20%, 30%, более 30%)

______________________________________________________________________

23. Ташламалар категориясе: ________________________________________ ☐

(бар/юк (астына сызарга) (36 бүлек коды)

______________________________________________________________________

(күрсәтергә:ташламага нигезне, ташлама төрен:

______________________________________________________________________

аварийщиклар, чернобыльчеләр,күп балалылар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар,

______________________________________________________________________

сәламәтлеге буенча, тузган торак,башкалар)

______________________________________________________________________

24. Мәшгульлек өлкәсендә гражданнарның квота категориясе: ______________ ☐

(37 бүлек коды)

______________________________________________________________________

(күрсәтергә: гариза бирүче гражданнарның кайсы категориясенә керә)

______________________________________________________________________

25. Таләп ителә торган торак төре
(теләгән): ______________________________________________________ ☐

(35 бүлек коды)

______________________________________________________________________

Раслыйм: әлеге гариза-анкетадагы мәгълүматлар түбәндә күрсәтелгән датага дөрес һәм тулы

Гариза бирүче: ______________________________________________________

(фамилия, исем,атасының исеме тулысынча, имза)

Гаиләнең хокуктан файдалануга сәләтле әгъзалары:

1.____________________________________________________

2.____________________________________________________

3.____________________________________________________

4.____________________________________________________

5.____________________________________________________

6.____________________________________________________

(Гаиләнең хокуктан файдалануга сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

"___________" ____________ 20__ ел

(дата сүз белән)

Кушымта № 3

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА БУЕНЧА ТОРАК ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУ ӨЧЕН ГАРИЗА БИРҮЧЕНЕ ҺӘМ АНЫҢ ГАИЛӘСЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТУРЫНДА МӘСЬӘЛӘНЕ КАРАУ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

1. Барлык гражданнар өчен гомуми нигезләрдә:
гражданның җирле үзидарә органы җитәкчесе яки оешма җитәкчесе исеменә гаризасы; (ТР МК ның 2015 елның 13 апрелендәге 250 номерлы Карары редакциясендә)
финанс-лицевой счет күчермәсе;
йорт кенәгәсеннән өземтә (-ләр);
торак шартларын тикшерү турында белешмә (тузган һәм авария хәлендәге торак өчен);
ордер (наем, ярдәмче наем, аренда, субаренда шартнамәсе);
гаиләнең барлык эшләүче әгъзаларының эш урыннарыннан) предприятиенең реквизитларын, гражданның эш урыны, аның вазыйфасы турында мәгълүматларны эченә алган һәм оешма җитәкчесе кул куйган һәм мөһер белән расланган белешмә (-ләр) (Россия Федерациясе законнары белән мөһере булырга тиешлеге билгеләнгән очракларда);
(ТР МК ның 2015 елның 12 сентябендәге 669 номерлы Карары редакциясендә)

барлык гаилә әгъзаларының керемнәрен раслаучы документлар:

-узган ел өчен хезмәт хакы турында белешмә (2-НДФЛ формасы буенча);

- керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә (Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган);
(ТР МК ның 2015 елның 12 сентябендәге 669 номерлы Карары редакциясендә)

-узган календарь ел һәм агымдагы календарь елның узган отчет чоры өчен салым инспекциясе тамгасы белән декларация (эшкуарлар өчен) яки алдан йөкләнгән керемне түләүгә (соңгы 6 ай өчен) күчкән эшкуарлар өчен алдан йөкләнгән керемгә салым түләү турында таныклык;

студент билеты яки уку урынын раслаучы документ (укучылар өчен);

стипендия алу турында белешмә (студентлар өчен);

пособиеләр алу турында белешмә;

Россия Федерациясе субъекты ягыннан субсидияләр булганда – субсидия бирүне гарантияләүче документлар;

милектә торак булуы турында яки аны (гариза бирүченең торак бинасында тору урыны буенча, шул исәптән Россиянең башка регионнарыннан да, соңгы 5 елда теркәлгән барлык затларга) читләштерү буенча килешүләрне гамәлгә ашыру турында белешмә;

торак бинага һәм җиргә хокук урнаштыручы документларның күчермәләре (торак бинага һәм җиргә милек турында таныклыклар, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итү шартнамәсе);

торак бинаның (фатирның) техник инвентарьлау бюросы биргән техник паспорты, күрше (күрше-аерып алынган) бүлмәләрдә яшәүчеләрнең исемлеге;

Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте Идарәсендә күчемсез милекне теркәү турында таныклык; (ТР МК ның 2015 елның 13 апрелендәге 250 номерлы Карары редакциясендә)
әлеге мәйданда яшәүчеләрнең барысының да паспорт мәгълүматлары (серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), ә гаиләнең балигъ булмаган әгъзаларына – туу турында таныклыкның;
призыв яшендәге ир-ат җенесендәге затлар өчен хәрби билет күчермәсе;
хезмәт стажын раслаучы хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (кадрлар бүлеге башлыгы тарафыннан расланган барлык битләре дә);
туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар: никахлашу (аерылышу) турында таныклык, балаларның туу турында таныклыгы, никах шартнамәсенең (контракт) булуы;
гариза бирүче һәм һәр гаилә әгъзасының ИНН (салым түләүченең таныклау номеры) күчермәләре.
(абзац ТР МК ның 2017 елның 30 сентябрендәге 740 номерлы Карары белән кертелгән)

2. Яшәү өчен яраксыз торакны биләүче гражданнар өчен:

1 пунктта санап кителгән документлар;

торакны яшәү өчен яраксыз дип тану турында район (шәһәр) хакимияте карары.

3. Ташламаларга ия гражданнар өчен:

1 пунктта санап кителгән документлар;

тиңдәшле ташламаны раслаучы дәүләт циркуляры;

тиңдәшле ташламаны раслаучы документлар: белешмәләр, таныклыклар;

өстәмә мәйданга хокукы булуны исәпкә алып чиратка бастырылучы затлар өчен әлеге хокук турында документлар.

Искәрмә. Зарурлык булганда махсуслашкан оешма (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы

Дәүләт торак фонды) гариза бирүче һәм аның гаиләсе әгъзалары хакында өстәмә мәгълүматлар белән документлар соратып алдырырга хокуклы.

.

Кушымта № 4

**ГАИЛӘЛӘР ИСЕМЛЕГЕНЕҢ УНИФИКАЦИЯЛӘНГӘН (БЕРДӘЙЛӘШТЕРЕЛГӘН) ФОРМАСЫН ТУТЫРУ ӨЧЕН ЗАРУРИ МӘГЪЛҮМАТЛАР**

| Бүлек номеры | Бүлекнең исеме |
|---|---|
| 1 | № п/п |
| 2 | Гаиләнең номеры |
| 3 | Гаиләнең учет делосының уникаль номеры |
| 4 | Гаилә әгъзаларының саны |
| 5 | Гариза бирүченең һәм гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча) |
| 6 | Туганлык мөнәсәбәтләре |
| 7 | Туу датасы |
| 7.1. | Туу урыны |
| ( 7.1 пункты ТР МК ның 2017 елның 30 сентябрендәге 740 номерлы Карары белән кертелгән) | |
| 8 | Шәхес таныклыгын раслаучы документ |
| 9 | Гариза бирүченең һәм һәрбер гаилә әгъзасының физик зат ИНН (салым түләүченең таныклау номеры) |
| 10 | Гариза бирүченең һәм һәрбер гаилә әгзасының мәшгульлеге |
| 11 | Эш, уку урыны |
| 12 | Оешманың ИНН |
| ( 12 пункт ТР МК ның 2015 елның 13 апрелендәге 250 номерлы Карары редакциясендә) | |
| 13 | Квота категориясе |
| 14 | Бюджеттагылар категориясе коды |
| 15 | Гаиләнең һәрбер эшләүче әгъзасының вазыйфасы |
| 16 | Эш стажы |
| 17 | Барлык торак бүлмәләрнең гомуми мәйданы нәтиҗәсеннән чыгып гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең җыелма дәрәҗәсе (кв. м) |
| 18 | Прописка датасы (шул исәптән вакытлыча булмаганнарның) |
| 19 | Учетка басу датасы |
| 20 | Учетка басуның соңгы кабаттан теркәлү датасы |
| 21 | Торакка хокук объектлары |
| 22 | Гражданнарның торак бинага милек хокукы һәм башка әйбергә иялек хокуклары |
| 23 | Торак фондының милек формасы |
| 24 | Гаиләнең бер әгъзасына уртача айлык керем |

| | |
|---|---|
| 25 | Билгән торак мәйданның төзеклек (уңайлылык)  стандарты |
| 26 | Район, шәһәр коды |
| 27 | Торак пунктның исеме |
| 28 | Урам исеме |
| 29 | Йорт номеры |
| 30 | Фатир, бүлмә номеры |
| 31 | Торак мәйданы (гомуми) |
| 32 | Торак (торырга яраклы) мәйданы |
| 33 | Бүлмәләр саны |
| 34 | Торак бинада гаиләләр саны |
| 35 | Тәүге взносны кертү мөмкинлеге |
| 36 | Торак бинаның гаиләгә таләп ителә торган мәйдан нормативы |
| 37 | Таләп ителә торган торак күренеше |
| 38 | Ташлама категориясенең коды |
| 39 | Ташлама хокукы барлыкка килү датасы |
| 40 | Гаиләне учеттан төшерү турында боерык  датасы һәм номеры |

Социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен гаиләләр исемлегенең унификацияләнгән (бердәйләштерелгән) формасы - кушымта № 5.

Унификацияләнгән формага  мәгълүматларны тутыру тәртибе 6 номерлы кушымтада бәян ителгән.

Искәрмә. Социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алынган гаиләләрнең локаль исемлеген төзүгә контроль буенча Татарстан Республикасы шәһәр һәм районнарының җирле үзидарә органнары хезмәтләре  гаиләләр исемлеге бүлекләрен тутырганда мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

Кушымта № 5

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА БУЕНЧА
ТОРАК ШАРТЛАРЫН ЯХШЫРТУГА МОХТАҖ ГАИЛӘЛӘР
ИСЕМЛЕГЕ

| ***№ п/п*** | ***Гаиләнең учет делосын теркәү датасы*** | ***Гаиләнең учет делосының номеры*** | ***Гаилә әгъзаларының саны*** | ***Гаилә әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча)*** | ***Туганлык мөнәсәбәтләре*** | ***Туу датасы*** | ***Туу урыны*** | ***Шәхеснең таныклыгы*** | ***Физик затның ИНН*** | ***Мәшгульлек*** | ***Эш, уку урыны*** | ***Предприятие ИНН*** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ***1*** | ***2*** | ***3*** | ***4*** | ***5*** | ***6*** | ***7*** | ***7.1*** | ***8*** | ***9*** | ***10*** | ***11*** | ***12*** |

| ***Квота категориясе*** | ***Бюджеттагылар категориясе коды*** | ***Вазыйфа*** | ***Эш стажы*** | ***Гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешенең җыелма дәрәҗәсе*** | ***Прописка датасы (шул исәптән вакытлыча булмаганнарның)*** | ***Учетка басу датасы*** | ***Учетка басуның соңгы кабаттан теркәлү датасы*** | ***Торак хокуклары объекты*** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ***13*** | ***14*** | ***15*** | ***16*** | ***17*** | ***18*** | ***19*** | ***20*** | ***21*** |

| ***Милек формасы*** | | ***Гаиләнең бер әгъзасына уртача айлык керем*** | ***Төзеклек (уңайлылык) стандарты*** | ***Яшәү адресы*** | | | | | ***Торак мәйданы, кв. м*** | | ***Бүлмәләр саны*** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ***торак бинага милек хокукы һәм башка*** | ***Торак фонды милке*** | | | ***район, шәһәр коды*** | ***торак пункт*** | ***урам*** | ***йорт номеры*** | ***фатир номеры*** | ***гомуми*** | ***Торырга яраклы*** | |

| *әйбергә иялек хокуклары* | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *22* | *23* | *24* | *25* | *26* | *27* | *28* | *29* | *30* | *31* | *32* | *33* |

| **Фатирдагы гаиләләр саны (аерым финанс-лицевой счет, хөкем карары)** | **Тәүге взносны кертү мөмкинлеге , % яки сум** | **Гаиләгә торак мәйданы нормативы** | **Таләп ителә торган торак күренеше** | **Ташлама категория сенең коды** | **Приоритет лар** | **Ташлама хокукы барлыкка килү датасы** | **учеттан төшү турында боерык датасы һәм номеры** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **34** | **35** | **36** | **37** | **38** | **37** | **39** | **40** |

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 гыйнварындагы “”2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алуга учетка басу һәм түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау хакында” 12пи номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.2)1 пунктның 1 абзацындагы “2014-2020” цифрларын “2014-2021” цифрларына алмаштырырга;

5.3) административ регламентның исемендәге “2014-2020” цифрларын “2014-2021” цифрларына алмаштырырга;

5.4) 1.1 пунктның 1 абзацындагы “2014-2020” цифрларын “2014-2021” цифрларына алмаштырырга;

5.5) 1.1 пунктның 2 абзацындагы “2014-2020” цифрларын “2014-2021” цифрларына алмаштырырга; “экономик класс торак бинасының” сүзләрен “стандарт торак” сүзләренә алмаштырырга;

5.6) 1.4 пунктның 7,8 абзацларындагы “2014-2020” цифрларын “2014-2021” цифрларына алмаштырырга;

5.7) 1 номерлы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Кушымта № 1.

____________________________
(җирле үзидарә органы)

Гариза

“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлыклары булган торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының һәм “2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү “ дәүләт программасының “2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” ярдәмче программасының “Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” төп чарасында катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга түбәндәге составтагы яшь гаиләне мохтаҗ дип тануны үтенәм:

ир: ____________________________________________________________,
(Ф.И.А.и. (булса), туу датасы)

паспорт: серия _______ № __________, бирелгән ______________________________
_____________________________________________ "___" ___________________ ел,
түбәндәг адрес буенча яши: ______________________________________________;

хатын: ____________________________________________________________,
(Ф.И.А.и. (булса), туу датасы)

паспорт: серия _______ № __________, бирелгән ______________________________
_____________________________________________ "___" ___________________ел.,
түбәндәге адрес буенча яши: ____________________________________________;

